КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 26 июль г.Казань № 651

Татарстан Республикасында, Россия Федерациясенең башка субъектларында, якын һәм ерак чит илләрдә «Сабантуй» татар халык бәйрәмен оештыру һәм үткәрү стандартын һәм Татарстан Республикасында, Россия Федерациясенең башка субъектларында, якын һәм ерак чит илләрдә «Сабантуй» татар халык бәйрәмен оештыру һәм үткәрү өчен Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән норматив чыгымнарны исәпләү тәртибен раслау турында

Татарстан Республикасында, Россия Федерациясенең башка субъектларында, якын һәм ерак чит илләрдә «Сабантуй» татар халык бәйрәмен үткәрүне тәртипкә салу максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Түбәндәгеләрне (карарга теркәләләр) расларга:

Татарстан Республикасында, Россия Федерациясенең башка субъектларында, якын һәм ерак чит илләрдә «Сабантуй» татар халык бәйрәмен оештыру һәм үткәрү стандартын;

Татарстан Республикасында, Россия Федерациясенең башка субъектларында, якын һәм ерак чит илләрдә «Сабантуй» татар халык бәйрәмен оештыру һәм үткәрү өчен Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән норматив чыгымнарны исәпләү тәртибен.

2. Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгына Татарстан Республикасында, Россия Федерациясенең башка субъектларында, якын һәм ерак чит илләрдә

«Сабантуй» татар халык бәйрәмен үткәрүгә норматив чыгымнар күләмнәрен билгеләгәндә бу карарга таянып эш итәргә.

3. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин